СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**12 июль 2016 ел** **№ 63**

**Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә карата хезмәт тикшерүләрен оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында**

Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупциягә каршы көрәш системасын алга таба камилләштерү максатларында, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Арча район Советы карар кылды:

1. Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә карата хезмәт тикшерүләрен оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
12.07. 2016 ел, №63 карары белән
**РАСЛАНДЫ**

## Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә карата хезмәт тикшерүләрен оештыру һәм уздыру тәртибе турында
## НИГЕЗЛӘМӘ

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә карата хезмәт тикшерүләрен оештыруга һәм үткәрүгә төп таләпләр билгели.

1.2. Хезмәт тикшерүе Арча муниципаль районының җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча үткәрелә.

1.3. Хезмәт тикшерүен уздырганда тулысынча, объектив һәм һәрьяклап билгеләнгән булырга тиеш:

- үзенә йөкләнгән вазыйфаи бурычларын үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү факты (законнар таләпләрен, хезмәт шартнамәсе буенча йөкләмәләр таләпләрен, эчке хезмәт күрсәтмәсе, вазыйфаи инструкция, Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актлары кагыйдәләрен бозу (алга таба - хокук бозулар);

- берничә муниципаль хезмәткәрнең дисциплинар гамәл кылган очракта, һәр муниципаль хезмәткәрнең гаебе яисә гаепләү дәрәҗәсе;

- муниципаль хезмәткәрләргә үзенә йөкләнгән функциональ вазыйфаларны үтәмәүгә яисә тиешенчә үтәмәүгә китергән сәбәпләр һәм шартлар;

- муниципаль хезмәткәрләргә йөкләнгән функциональ вазыйфаларны үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү нәтиҗәсендә китерелгән зыянның (зыянның) характеры һәм күләме;

- хезмәт тикшерүен үткәрү өчен нигез булып торган хәлләр.

1.4 Хезмәт тикшерүе Арча муниципаль районының җирле үзидарә органы җитәкчесе күрсәтмәсе нигезендә төзелгән комиссия тарафыннан үткәрелә.

### 2. Хезмәт тикшерүен үткәрү өчен нигезләр

2.1.Хезмәт тикшерүен үткәрү өчен түбәндәгеләр нигез була:

- бозу турында акт;

Доклад язуы;

- гражданнарның, оешмаларның мөрәҗәгатьләре (хәбәрләре);

- муниципаль хезмәткәрнең аңа тап төшерә торган белешмәләрне кире кагу турында гаризасы;

- җирле үзидарә органының муниципаль хезмәткәрен дисциплинар җаваплылыкка тарту таләбе белән прокурор реакциясе акты.

2.2. Хокук бозу турындагы актта түбәндәге белешмәләр күрсәтелергә тиеш:

- акт төзү датасы, вакыты һәм урыны;

- тәртип бозу турында акт төзелә торган муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы;

- хокук бозуларны башкару (ачыклау) урыны һәм вакыты;

- хокук бозуны кылу шартлары;

- фамилияләрен, исемнәрен, атасының исемен, шулай ук акт төзегән затларның вазыйфаларын;

- акт төзегән затларның имзалары.

Хокук бозу турындагы акт, кагыйдә бозуны ачыклаган затларны да кертеп, кимендә өч зат тарафыннан имзалана.

2.3. Хокук бозу факты булган доклад язуында, әлеге тәртипнең 2.2 пунктында санап үтелгән мәгълүматлардан тыш, хокук бозу фактын расларга мөмкин булган затлар турында белешмәләр күрсәтелә.

Доклад язуына хокук бозу фактларын раслый торган документлар теркәлә (алар булган очракта).

2.4. Акт яки доклад язмасы төзелергә мөмкин:

2.4.1. Җирле үзидарә органының тиешле структур бүлекчәсе җитәкчесе (муниципаль хезмәткәрләргә үз вазыйфаи бурычларын бозу (бозу мөмкинлеге) турында теләсә нинди чыганаклардан мәгълүмат кергән очракта.

## 3. Хезмәт тикшерүен үткәрү тәртибе

3.1. Хезмәт тикшерүе җирле үзидарә органы җитәкчесенең әлеге тәртипнең 2.1 п. күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән алып биш эш көне эчендә билгеләнеп куела.

Күрсәтмәне әзерләү җирле үзидарә органының кадрлар эше алып баруга вәкаләтле структур бүлекчәсенә (вазыйфаи затка) йөкләнә.

3.2.Муниципаль хокукый акт хезмәт тикшерүен үткәрүгә бәйле рәвештә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- хезмәт тикшерүе үткәрелергә тиешле муниципаль хезмәткәрнең фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын;

- хезмәт тикшерүен үткәрү өчен нигезләр;

- хезмәт тикшерүен үткәрү комиссиясе составы;

- хезмәт тикшерүен үткәрү сроклары;

- муниципаль хезмәткәрне, кирәк булганда, биләгән вазыйфасы буенча хезмәт хакын саклап калып, хезмәт тикшерүен уздыру чорына вазыйфаи бурычларын үтәүдән вакытлыча читләштерү турында күрсәтмә.

3.3. Хезмәт тикшерүен үткәрү турында күрсәтмә мәҗбүри тәртиптә хезмәт тикшерүен үткәрү буенча комиссиянең барлык әгъзаларына (алга таба - комиссия), шулай ук хезмәт тикшерүе үткәрелә торган муниципаль хезмәткәргә җиткерелә.

3.4. Хезмәт тикшерүе җитәкче билгеләгән вакытта, әмма хезмәт тикшерүе билгеләнгән көннән соң 15 эш көненнән дә соңга калмыйча тәгалләнергә тиеш.

3.5. Хезмәт тикшерүе барышында муниципаль хезмәткәрдән язма аңлатмалар таләп ителергә тиеш.

3.5.1. Муниципаль хезмәткәр язма аңлатмалардан баш тарткан очракта, хокук бозуны кылуның асылы буенча язмача аңлатма бирүдән баш тарту турында акт төзелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- акт төзү урыны, көне һәм вакыты;

- акт төзи торган вазыйфаи затның һәм язма аңлатмалардан баш тартканда шунда булган хезмәткәрләрнең вазыйфасы, фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (әгәр андыйлар булса);

- акт төзелә торган муниципаль хезмәткәрнең вазыйфасы, фамилиясе, исеме һәм атасының исеме;

- муниципаль хезмәткәрнең язма аңлатмалардан баш тартуы сәбәбе (ирекле рәвештә).

Акт аны төзегән зат һәм комиссиянең ике әгъзасы йә акт төзелә торган хезмәткәрләргә язмача аңлатмалардан баш тартканда шунда булган башка хезмәткәрләр тарафыннан имзалана.

3.5.2. Комиссия таләбе буенча язма аңлатмаларны бозуга катнашы булган башка хезмәткәрләр дә тәкъдим итәргә тиеш.

3.6. Хезмәт тикшерүе үткәрелә торган муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләргә хокуклы:

- аңа карата үткәрелә торган хезмәт тикшерүенең нигезләре, фактлары һәм шартлары буенча үз фикерен бәян итеп, язма аңлатмалар бирергә, гаризаны, үтенечнамәләрне һәм башка документларны тапшырырга,

- комиссия рәисенә үзе тапшыра торган документларга хезмәт тикшерүе материалларын кушып бирүне сорап мөрәҗәгать итәргә;

- комиссия әгъзаларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерергә;

- хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча язма бәяләмә һәм башка материаллар белән танышырга;

- хезмәт тикшерүен үткәрү йөкләнгән затларга мотивлаштырылган отводлар бирергә.

3.7. Хезмәт тикшерүен уздырганда комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

- хезмәт тикшерүе үткәрелә торган муниципаль хезмәткәргә, шулай ук дисциплинар гамәл шартлары турында нинди дә булса белешмәләр билгеле булырга мөмкин муниципаль хезмәткәрләргә язмача аңлатмалар, шулай ук хезмәт тикшерүе мәсьәләләренең асылы буенча башка мәгълүмат бирергә;

- махсус белем таләп итә торган мәсьәләләр буенча белгечләрдән консультацияләр алырга;

- кирәкле документларны (мәгълүматны) дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына, оешмаларга тапшыру, аларга җаваплар алу һәм аларны хезмәт тикшерүе материалларына теркәп кую турында билгеләнгән тәртиптә запрослар җибәрергә.

3.8. Хезмәт тикшерүен уздырганда комиссия түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

- хезмәт тикшерүе үткәрелә торган муниципаль хезмәткәрнең һәм хезмәт тикшерүендә катнашучы башка затларның хокукларын үтәргә;

- хезмәт тикшерүе материалларының сакланышын һәм конфиденциальлеген тәэмин итәргә, аның нәтиҗәләре турындагы белешмәләрне фаш итмәскә;

- хезмәт тикшерүен уздыру срокларын үтәргә һәм объективлыкны тәэмин итәргә.

## 4. Комиссия эшен оештыру

4.1. Хезмәт тикшерүен үткәрү комиссиясе (алга таба - комиссия) Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкилләреннән төзелә.

4.2. Комиссия составына түбәндәге нигезләрдә муниципаль хезмәткәрләр кертелә алмый:

- әгәр алар хезмәт тикшерүе үткәрелә торган муниципаль хезмәткәргә хезмәт буенча буйсынучы булса;

- әгәр алар хезмәт тикшерүе үткәрелә торган муниципаль хезмәткәрнең туганнары булса;

- хезмәт тикшерүе нәтиҗәләрендә ул турыдан-туры яисә читләтеп кенә кызыксынган булырга мөмкин дип уйларга нигез булырлык шартлар булса, яисә аның объективлыгында һәм гаделсезлегендә шик тудыра торган башка нигезләр булса.

Күрсәтелгән таләпне үтәмәгәндә хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре дөрес түгел дип санала.

4.3. Хезмәт тикшерүен үткәрү комиссиясе комиссия рәисеннән һәм комиссиянең ике яисә аннан да күбрәк әгъзасыннан тора.

4.4. Комиссия рәисе комиссия эшен оештыра һәм хезмәт тикшерүен уздыруның срокларын, тулылыгын һәм объективлыгын үтәү өчен җаваплы.

## 5. Хезмәт тикшерүе нәтиҗәләрен рәсмиләштерү

5.1. Хезмәт тикшерүен гамәлгә ашыручы комиссия билгеләнгән вакытта аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә төзи.

5.2. Бәяләмә әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә рәвеш буенча хезмәт тикшерүе материалларында булган мәгълүматларга нигезләнеп төзелә.

5.3. Хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча бәяләмәгә комиссиянең барлык әгъзалары имза сала һәм хезмәт тикшерүе үткәрелә торган муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә кушып бирелә.

5.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе, комиссия бәяләмәсе нигезендә, ике эш көне дәвамында хезмәткәргә карата билгеләнгән тәртиптә дисциплинар түләтүне куллану яки күралмау турында карар кабул итә.

5.5. Җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча хезмәт тикшерүе материаллары хокук саклау органнарына җибәрелергә мөмкин (әгәр административ яисә җинаять җаваплылыгы каралган хокук бозу составы билгеләре булса).

5.6. Җирле үзидарә органының кадрлар эше алып баруга вәкаләтле структур бүлекчәсе белгече җирле үзидарә органы җитәкчесе карар кабул иткән көннән алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча хезмәт тикшерүе үткәрелгән муниципаль хезмәткәрне аңа кагылышлы өлешендә хезмәт тикшерүенең бәяләмәсе һәм башка материаллары белән таныштыра.

5.7. Хезмәт тикшерүе материаллары хезмәт тикшерүен үткәрү турындагы эшкә төзелә, аңа түбәндәгеләр кушып бирелә:

- хезмәт тикшерүен билгеләү өчен нигез булып торучы документ (яисә аның күчермәсе);
- хезмәт тикшерүен билгеләү турында муниципаль хокукый акт күчермәсе;
- хезмәт тикшерүе үткәрелгән муниципаль хезмәткәрнең язма аңлатмалары;
- муниципаль хезмәткәрләрнең һәм башка затларның аңлатмалары;

- хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча комиссия бәяләмәсенең аңа карата хезмәт тикшерүе үткәрелгән муниципаль хезмәткәрне танышу турындагы белешмәләр белән күчермәсе;

- җирле үзидарә органының дисциплинар түләтү чараларын куллану турында күрсәтмәсенең күчермәсе (мондый карар кабул ителгән очракта);

- үткәрелгән хезмәт тикшерүенә катнашы булган башка документлар.

5.8. Эш материаллары номерлана, тегелә, алар буенча тасвирлама төзелә. Сформалаштырылган эшләр җирле үзидарә органының гамәлдәге законнарда билгеләнгән сроклар дәвамында кадрлар эше алып баруга вәкаләтле структур бүлекчәсендә саклана.

*Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә карата хезмәт тикшерүләрен оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымта*

**Хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча бәяләмә**

1. Хезмәт тикшерүен үткәрү нигезләре:

______________________________________________________________________________

(хезмәт тикшерүен үткәрү турында карар кабул итүнең нигезе һәм датасы күрсәтелә)

2. Хезмәт тикшерүе түбәндәге составта комиссия тарафыннан үткәрелә:

______________________________________________________________________________

(Ф.И.А.и., муниципаль хезмәт вазыйфасы)

3. Хезмәт тикшерүен үткәрү датасы:

______________________________________________________________________________

(башланды) (тәмамланды)

4. Хезмәткә тикшерү үткәрелгән муниципаль хезмәткәр турында белешмәләр:

______________________________________________________________________________

(хезмәт тикшерүе үткәрелгән муниципаль хезмәткәрнең вазыйфасы

5. Муниципаль хезмәткәрләргә дисциплинар гамәл кылу, аларны башкаруга китергән сәбәпләрне һәм шартларны, китерелгән зыянның характерын һәм күләмен кыскача тасвирлау:

______________________________________________________________________________

6. Хезмәт тикшерүе уздырылган муниципаль хезмәткәрнең аңлатмалары:

______________________________________________________________________________

7. Хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча бәяләмә:

______________________________________________________________________________

8. Муниципаль хезмәткәргә дисциплинар түләтүне куллану яисә аларның кулланылмавы турындагы тәкъдимнәр:

______________________________________________________________________________

Комиссия рәисе
хезмәт тикшерүен үткәрү ___________________________
(имза) (имзаны аңлату)

комиссия әгъзалары
хезмәт тикшерүе:
(имза) (имзаны аңлату)

_______________ ________________________________

(имза) (имзаны аңлату)

_______________ ________________________________

(имза) (имзаны аңлату)

_______________ ________________________________

(имза) (имзаны аңлату)

"___"___________ 20_____ ел

Бәяләмә белән таныш____________________________________
(Үзенә карата хезмәт эшчәнлеге башкарылган муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.А.и.)